ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЧУВАШСКО-ДРОЖЖАНОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Улица Октябрьская, дом 21а,

Село Чувашское Дрожжаное, 422485

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЧУАШ ЧҮПРӘЛЕСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШГАРМА

Октябрь урамы,21нче йорт,

Чуаш Чупрелесе авылы,422485

Тел.: 8(84375)3-72-48, 8(84375)3-72-23, факс: 8(84375)3-72-48, Chuvd.Drz@tatar.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2019 нчы елның 4 феврале №3

Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Чуаш Чүпрәле
авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлеккә
булышлык итү һәм үстерү буенча
Координацион Совет төзү турында

2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында”гы, 2003нче елның 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары” Федераль Законнары, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Чуаш Чүпрәле авыл җирлегенең Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Чуаш Чүпрәле авыл җирлеге башкарма комитеты карар итә:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Чуаш Чүпрәле авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык итү һәм үстерү буенча Координацион Совет төзергә (Кушымта № 1).

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Чуаш Чүпрәле авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык итү һәм үстерү буенча Координацион Совет төзү турындагы нигезләмәне расларга (Кушымта №2).

3. Бу карарны Чуаш Чүпрәле авыл җирлеге территориясендә булган махсус мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый порталы мәгълүмати-телекоммуникацион «Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

Чуаш Чүпрәле авыл җирлеге башлыгы: В.В.Землемеров

Кушымта №1
Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Чуаш Чүпрәле
авыл җирлеге башкарма
комитетының 3 номерлы карарына
4 февраль 2019 нчы ел

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Чуаш Чүпрәле авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык итү һәм үстерү мәсьәләләре буенча Координацион Совет составы**

Координацион Совет рәисе- Чуаш Чүпрәле авыл җирлеге башлыгы вазыйфасын башкаручы Землемеров Виталий василий улы;

Координацион Совет рәисе урынбасары – шәхси эшмәкәр (килешү буенча) Аръяхов Владимир Владимир улы;

Координацион Совет сәркатибе, Чуаш Чүпрәле авыл җирлеге башкарма комитеты сәркатибе - Хемницер Алевтина Дмитрий кызы;;

Шәхси эшмәкәр (килешү буенча) - Шленский борис Николай улы;

Шәхси эшмәкәр (килешү буенча) - Калашникова Наталия Николай кызы.

Кушымта № 2

Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Чуаш Чүпрәле
авыл җирлеге башкарма
комитетының 3 номерлы карарына
4 февраль 2019 нчы ел

**Нигезләмә**
**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Чуаш Чүпрәле авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык итү һәм үстерү мәсьәләләре буенча Координацион Совет турында нигезләмә**

**Гомуми кагыйдәләр**

Бу нигезләмә 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында"гы Федераль Законы нигезендә төзелде. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Чуаш Чүпрәле авыл җирлеге Координацион Советы җәмгыять оешмаларының һәм эшмәкәрлек даирәсе вәкиллегенең базар икътисады шартларында кече һәм урта эшмәкәрлекнең төп юнәлешләрен билгеләүдә даими эшли торган консультатив-киңәш органы булып санала.

Координацион Совет юридик зат булып саналмый һәм үзенең эшчәнлеген җәмгыяви башлангычта алып бара.

Координацион Совет үзенең эшчәнлегендә Россия Федерациясе законнарына һәм әлеге нигезләмәгә таяна..

Координацион Совет үзенең эшчәнлеген дәүләт оешмалары, районның җирле үзидарә органнары, иҗтимагый оешмалар һәм эшмәкәрлек структуралары белән килешеп башкара.

**II. Төп мәсьәләләр**

Координацион Советның төп мәсьәләләре:
- дәүләтнең икътисадый сәясәтен тормышка ашырганда дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә һәм эшмәкәрлек субъектлары эшчәнлегенең бердәм эшләвен тәэмин итә;
- авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык итү һәм үстерүдәге дәүләт ярдәменең өстенлекле юнәлешләрен, принципларын, стратегиясен төзү.
- Россия Федерацисе һәм Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык итү һәм үстерүгә юнәлдерелгән законнарын һәм башка норматив хокукый актларын төзү һәм тормышка ашыруда ярдәм итү;

- кече һәм урта эшмәкәрлек үсешенең уңай тәҗрибәсен, максат һәм бурычларын пропагандалау.

**III. Функцияләр**

Координацион Совет төп мәсьәләләргә яраклаштырып, түбәндәге функцияләрне үти:

- авыл җирлегендәге кече һәм урта эшмәкәрлек торышының мониторинг нәтиҗәләрен карый;;
- кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык итү һәм үстерүнең стратегия һәм тактикасы буенча авыл җирлеге башлыгына тәкъдимнәр кертә;
- алдынгы технологияләр һәм идарә итү тәҗрибәсе, инвестицияләрне җәлеп итү һәм куллану буенча тәкъдимнәр бирә;
- кече һәм урта эшмәкәрлек эшчәнлегенең төрле мәсьәләләрен, гамәлдәге кануннарын җайга салудагы тәкъдимнәрен эшкәртә, Татарстан Республикасының республика законнары проектларын һәм башка норматив хокукый актларын экспертиза үткәрүне оештыра;
- кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә юнәлдерелгән проектларны карый һәм республика программалары үтәлеше барышын анализлый;
- кече һәм урта эшмәкәрлекнең әһәмиятен үстерүгә юнәлтелгән мәгълүмати тирәлек булдыруга, эшмәкәрлек иницативасын үстерүгә, эшмәкәрләрнең икътисадый формаларны эшкәртү һәм тормышка ашыру процессына этәргеч ясый.

## IV. Хокуклар

Төп мәсьәләрне хәл итүдә Координацион Советның хокуклары::
- Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Чуаш Чүпрәле авыл җирлегенең кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык итү һәм үстерүдәге карар проектларын әзерләүдә катнашырга;
- Координацион Совет эшенә кирәк булган хуҗалык итү субъектлары мәгълүматларын башкарма хакимият органнарыннан сорарга;
- кирәк вакытта белгечләрне , билгеләнгән тәртиптә, консультантлар сыйфатында файдаланырга;
- билгеләнгән тәртиптә, конкрет мәсьәләләрне хәл итү өчен эшче группалар булдырырга һәм аларның эш тәртибен билгеләргә;
- авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүдәге көнүзәк проблемалар буенча аналитик язмалар хәзерләргә.

## V. Эшчәнлекне оештыру

Координацион Советны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Чуаш Чүпрәле авыл җирлеге башлыгы җитәкли. Координацион Совет составына җәмгыять берләшмәләре органнары тарафыннан билгеләнгән Чуаш Чүпрәле авыл җирлеге башкарма хакимият вәкилләре һәм кече һәм урта эшмәкәрлек вәкилләре тигез хокукта керәләр. Координацион Совет утырышлары, рәис тарафыннан расланган план нигезендә, кварталга бер тапкырдан да ким үткәрелми. Координацион Совет әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашканда гына ул үз көченә ия була. Утырышны үткәрү вакыты, урыны һәм көн тәртибе турындагы мәгълүмат утырыш әгъзаларына утырыш башланырга өч көн алдан җиткерелергә тиеш. Координацион Совет карарлары ачык тавыш бирү юлы һәм утырышта катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә.Тавышлар тигез булганда, Координацион Совет рәисе тавышы хәлиткеч санала. Координацион Советны таркату Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Чуаш Чүпрәле авыл җирлеге башкарма комитеты карары нигезендә башкарыла.